# Тукай – Мулла Илендә

Тукай – Мулла Илендә // Ватаным Татарстан,15.08.2015, № 119.

Габдулла Тукай белән якыннан аралашу бәхетенә ирешкән зыялылар арасында Мулла Иле кешесе Гыйззәтулла Хәйрулла улы Галиәкбәров (1885-1911) та бар.

Гыйззәтулла гыйлемгә бик тә һәвәс, зирәк бала булып үскән, авылның мулласы Вәлихәйдәр хәзрәт Котлыәхмәтовтан төпле белем алган. Бу хәзрәтнең биографиясе мәшһүр галимебез Шиһабетдин Мәрҗани белән бәйле. Яшь чагында ул Казанда Мәрҗани мәдрәсәсендә укыган, Мәрҗанинең иң яраткан шәкерте булган. Укып бетергәч, 1874 нче елда аны Мулла Иле мәчетенә мулла итеп Мәрҗани үзе җибәргән. Бу мәчет Мәрҗани кушуы буенча Казанның атаклы сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Казаков тарафыннан әле 1873 нче елда гына төзелеп беткән була. Бу мәчеттә Вәлихәйдәр хәзрәт берөзлексез 1915 нче елга кадәр хезмәт итә. Хәзрәт Мәрҗанинең вафатына чаклы, 1889 нчы елга кадәр үзенең бөек остазы белән гел элемтәдә яши. 1880 нче елда Мәрҗани үзе дә Мулла Иленә килеп чыга, мәчеткә кереп, үзенең кадерле кулъязмаларын, саклар өчен, ышанычлы шәкертенә тапшырып киткән. Бу мәчет бүген дә урынында нык тора, бөтен куәтенә эшли. Бу мәчеттә миңа да мулла булып эшләргә насыйп булды.

Вәлихәйдәр хәзрәт үзенең сөекле шәкерте Гыззәтулланы укырга Казан укытучылар мәктәбенә илтеп урнаштыра. 1876-1917 нче елларда эшләгән бу урта уку йортына 16 яшьлек татар егетләре кабул ителгән һәм алар, укып бетергәч, татар авылларына рус теле укытучылары итеп җибәрелгәннәр. Уку вакыты дүрт ел булган. Укыту программасында рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты, математика, табигать, география, тарих, педагогика, рәсем, дин белемедәресләре мәҗбүри итеп куелган.

Галиәкдәров биредә, фәннәрне тирәнтен үзләштерү белән бергә, XX йөз башындагы яңарыш хәрәкәтенә җаны-тәне белән кушылып, җәмәгать эшләрендә кайнап яши. Сабакташы – булачак зур язучы Гаяз Исхакыйны аеруча тякын итә, ул оештырган яшерен түгәрәккә йөри. Сабакташы – булачак күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист Шакир Мөхәммәдьяров (1883-1967) белән гомерлек дус булып китә. Бу шәхес аны соңыннан Габдулла Тукай белән таныштыра. Бу болай була. Мәктәпне тәмамлагач, Шакир Казанда кала. “Болгар” кунакханәсендә яшәп, шунда урнашкан “Әльислах» газетасы редакциясендә эшли. Казанга Тукай килеп, ул да монда тора башлагач, Шакир белән шагыйрь, бер-берсенең бүлмәләренә керешеп, дусларча яши башлыйлар. Галиәкбәров исә, Мулла Иленә кайтып, мәчет каршында гына торган үз йортында яңача укыта торган рус-татар мәктәбе ача, тиз арада бөтен өяздә оста һәм кыю педагог булып таныла. Казандагы хәйрия җәмгыятенең бихисап эшләрен башкара, йөзләрчә ярлыларга ярдәм оештыра. Казанга бер килүендә Шакир аны Габдулла Тукай белән таныштыра. Бу – Тукайның, бар дөньясын онытып, мәктәпләр өчен дәреслек төзеп яткан чагы була. Тукай Гыйззәтулланы бер хәзинә итеп кабул итә. Әлеге кыю, талантлы педагог белән рәхәтләнеп уртак тел таба. Мәктәптә әдәби уку дәресләре өчен әзерләнгән хрестоматиясенә карата аңардан киңәшләр сорый.

Көннәрдән беркөнне, 1910 нчы елның җәендә, Гыйззәтулла Тукайны Мулла Иленә кунакка, дөресрәге педагогик эшчәнлеген күрсәтергә алып кайта.

Бу хәл турында миңа авылыбызның зыялы аксакалы Сәләхетдин абый Моратов сөйләгән иде. Ул кечкенә чагында Галиәкбәров мәктәбендә укыган. Аларның йортлары

мәктәп каршында гына булганлыктан, дәресләрдән соң да бик еш монда кереп йөргән ул. Бик тә тере, шук һәм зирәк бу шәкертен мөгаллиме һәрвакыт җылы каршылаган.

Беркөнне, кичкә каршы, урамда уйнаганда, Сәләхетдин тарантаслы ат килгәнен күрә. Кучер атны мәктәп капкасы алдында туктата. Тарантаста Гыйззәтулла абыйсы янында шәһәрчә киенгән бер ят кеше була. Менә алар, сөйләшә-сөйләшә, йортка кереп китәләр. Берәр сәгатьтән соң алар янына, әрсезләнеп, Сәләхетдин барып керә. Кунак абый аның белән кул биреп күрешә: "Мин – Габдулла Тукаев булам, ә үзең кем буласың?" – ди. Бер дә каушый торганнардан булмаса да, бу юлы шәкерт югалып кала. Аннары, үзен кулга алып: "Сез Тукай абыйның үземе?" – дип сорап куя. Бераздан Сәләхетдин: "Тукай абый, без сезнең китапны бик яратып укыйбыз!" – дип, өстәл өстендә яткан "Габдулла Тукаев. Уку китабы" дигән дәреслекне шагыйрьгә китереп бирә. Тукай, бик дулкынланып, үзе төзегән дәреслекне кулына ала: " Рәхмәт, матур егет, – дип, Сәләхетдиннең башыннан сыйпый, – син бик бәхетле, сине чын кеше укыта... Яле бер шигырь сөйләп күрсәт әле, энекәш," – ди. Сәләхетдин Тукай абыйсына "Ата илә бала" ("Кара такта янында") дигән шигырен сөйләгән;

Яз, газиз углым, кара тактаны сыз акбур белән!
Һәм кара күңлеңне ялт иттер ак нур белән!

Бераздан Тукай белән Гыйззәтулла мәчеткә керәләр, үзләре белән Сәләхетдинне дә ияртәләр. Тукай Вәлихәйдәр хәзрәт белән күптәнге танышы кебек кочаклашып күрешә, аннары, гаять дәрәҗәдә кызыксынып, хәзрәттән Шиһабетдин Мәрҗани турында сораша, хәзрәтнең истәлекләрен тын да алмыйча тыңлап тора һәм язып та бара.

Икенче көнне иртә белән Сәләхетдин мәктәпкә тагын керә, ләкин инде Тукай белән Гыйззәтулла Казанга китеп барганнар була. Тукай төн кунган бүлмәдә тып-тын уйланып торганда, шәкертнең күзе карандаш белән язылган шигырьгә төшә. Моны Тукай абыйсы язып калдырган була. (Шагыйрьнең бу сәер гадәте турында истәлекләрдә күп искә алына.) Сәләхетдин абый миңа шигырьне сөйләп тә күрсәткән иде. Бер генә кисәге исемдә калган:

Агай үрә чабата,
Үрә-үрә таң ата...

Тукай иҗатында Мулла Иле дигән сүз юк. Ләкин Мулла Иленә килеп киткәннән соң язылган бер шигырендә мондый юллар бар:

Читтәге бик күп өяздә,
Күр, авыллар яктыра.
Пар, тату йолдыз кеби,
Школ белән мәктәп тора.

Бу ике дус, чөнки берсенә
Аларның берсе тиң,
Бертигез тәгълимнәре дә:
Берсе – дөнья, берсе – дин.

Тукай моны язганда, Мулла Илендә үзе күреп киткән мәчеттәге дини мәдрәсәне һәм мәчет янында торган дөньяви мәктәпне – Галиәкбәров мәктәбен күздә тоткандыр.

"Шиһап хәзрәт" дигән атаклы мәдхиясен иҗат иткәндә дә, Мулла Иле мәчетендә булган чакта Мәрҗани турында ишеткәннәре шагыйрьнең колагында яңгырап торгандыр.

Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,

Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.

Әйе, Мәрҗани Вәлихәйдәр хәзрәтне тәрбияләгән. Вәлихәйдәр хәзрәт – Галиәкбәровны, Галиәкбәров – Сәләхетдинне. (Ул да авылда мулла булып торды.)

Яңача укытуны башлап йөргән талантлы педагог һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Галиәкбәровның гомере кыска була: 1911 нче елда, иҗаты чәчәк аткан вакытта, ул кинәт вафат була. Шакир Мөхәммәдьяров "Вакыт" газетасында зур күләмле хушлашу мәкаләсе бастыра. "Бөтен Тау Ягы җирләренә мул итеп бәхет орлыкларын чәчеп калдырган, яңа мәгарифкә кыю рәвештә юл ачкан чын зыялы педагог" дип атый ул аны.

Мөхәммәдьяров Казаннан Петербурга күчкәч, анда "Нур" газетасы редакциясендә эшли. Тукай 1912 нче елда Петербурга баргач, иң әүвәле, чиксез шатланып, аның янына керә. Әлбәттә, алар безнең Галиәкбәровны да искә алалар. Тукайның күз алдыннан безнең Мулла Иле дә чагылып үткәдер.

Моннан 142 ел элек Мәрҗани кушуы бунча төзелгән мәчетебез бүген дә, тулы куәтенә эшләп, урынында нык тора. Халкыбыз аны кадерләп саклый. Миңа да биредә мулла булып эшләргә насыйп булды. Мәчеткә кергән саен, мин монда җуелмас эзләре калган тарихи шәхесләребезне күргәндәй булам. Каюм Насыйри, монда булып, Мулла Иле тарихы турында фикер уртаклашкан, Баһаветдин Вәисов монда дини әсәрләрен укыган. Аның улы Гайнан Вәисов, көрәшләрдән арыган чагында, туган авылына кайтып монда кереп, күңеленә тынычлык тапкан. Тукай белән Гайнан арасында мөнәсәбәтләр катлаулы булган. Тукай "Кисекбаш" поэмасында Гайнанны Дию пәрие итеп сурәтләгән. Шул ук вакытта Тукайның яраткан язучысы Лев Толстой Гайнанны, үзенең утарына чакырып, өч көн буе кадерләп кунак иткән һәм "Мине игелекле мөселман итеп атагыз!" – дип озатып калган.

Иң каһәрле 1930 нчы елда, бөтен җирдә мәчет манаралары аударылган чакта, мәчетебезгә тикшерү өчен Казаннан легендар шагыйрь Һади Такташ килә һәм шакката: монда мәчет манарасы горур тора, гыйбадәтләр тулысынча башкарыла, монда хәтта коммунистлар да мәчеткә килеп намаз укыйлар.

Мулла Иле авылы булсын да,
Коммунистлар динле булмасын.
Мулла Иленең һәрбер коммунисты
Алмашырлык авыл мулласын! – дип башланып киткән шигырь. Һади Такташ, Казанга кайткач, шигырьне "Чаян" журналында бастыра.

Бүген Мулла Илендәге иң төзек, иң матур урам – Габдулла Тукай урамы. Монда туып үскән атаклы галимебез, профессор, шагыйрь Гомәр Саттаров иҗатында Габдулла Тукай зур урын алып тора. Унынчы класста укыганда ук Тукайга багышлап язган поэмасы район газетасы премиясенә лаек була. Ә инде Казан университетында студент чагында ул Тукай стипендиясен алып укый. (Сугыштан соңгы елларда Тукай исемен әнә ничек зурлаганнар, хәзер дә бу турыда уйланасы иде.).

***Равил Сәйфетдинов***

"Ватаным Татарстан" газетасында бастырылган мәкалә, 15.08.2015, № 119.

**Тукай һәм Тау ягы**

Тукай һәм Тау ягы // Яшел Үзән, 2018, 25 апрель, №29.

Халкыбызның бөек улы Габдулла Тукай турында сүз барганда:"Аны мәшһүр Казан арты биргән!" – дип кенә җибәрәбез, Тау ягы турында искә дә алмыйбыз.

Һәр ягы урман булган атаклы Кырлайдан киткәч, Тукай унике ел буе Җаекта яши, монда аны, нәкъ Кырлай авылы кебек үк, үзенең урманнары белән данлыклы Кайбыч авылында – Тау ягының гүзәл бер почмагында туып үскән Мотыйгулла хәзрәт кеше итә: ул аны үзенең мәдрәсәсендә ун ел буе укыта, рухи остазы, мөгаллиме, тәрбиячесе була. Мотыйгулла хәзрәттә укып, Тукай гүзәл нәтиҗәләргә ирешә: гарәп, фарсы, төрек телләрен иң камил дәрәҗәдә үзләштерә, изге Коръән Шәрифне гаять тирәнтен өйрәнеп, гаять матур мәкам белән укыган. Укыган бер аятен шунда ук татарчага тәрҗемә итеп бара алган, фән нигезләрен тирәнтен һәм төпле үзләштереп, дин һәм фән бергәлеген камил аңлау дәрәҗәсенә күтәрелгән; рус телен һәм әдәбиятын татар теле шикелле үк тирәнтен үзләштергән, Пушкинның "Подражания к Корану" ("Коръәнгә иярүләр") дигән әсәрен укып, бик нык тәэсирләнгән.

Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил Мотыйгый (1883-1941) шагыйрьнең дусты, фикердәше һәм эчкерсез ярдәмчесе булган. Мотыйгыйлар шул заманда бөтен татар иле өчен бәяләп бетергесез зур эш башкарганнар:"Фикер" газетасын һәм "Әлгасрелҗәдит", "Уклар" журналларын чыгарганнар. Тукай өчен киң әдәбият мәйданы ачылган. Нәкъ менә шул мәйданда зур шагыйрьгә әверелеп, Тукай Казанга килгән.

Тукай белән Камил Мотыйгый арасында зур охшашлыклар бар: икесе дә талант ияләре, икесе дә гаять моңлы җырлыйлар. Камил үзенең концертлары белән бөтен Рәсәйне гизеп чыккан, ул да Тукай шикелле әдәби әсәрләр язган. Мәсәлән, "Безнең Мәрьям» дигән романы 1904 нче елда басылып чыккан. Ул Коръән Кәримнең татарчага тәрҗемәсен дә ясаган, бу хезмәте 1904 нче елда дөнья күргән. (Бу хезмәт "Шура" журналында басыла башлады: 2016 нчы ел, №14)

Димәк, Тау ягының йөзек кашы булган Кайбыч авылыннан чыккан кешеләр Тукайны тәрбияләп, аңа иң югары дәрәҗәгә ирешергә юл ачканнар икән. Шулай булгач, Тукай әсәрләре тукымасында Казан арты сөйләме генә ятмый. Мотыйгулла хәзрәтнең сөйләмендә, әлбәттә, Кайбыч ягы үзенчәлекләре нык сизелеп торгандыр, һәм бу – ун ел буе уку дәверендә Тукайга да йогынтысын ясагандыр. Шулай булгач, Тукай әсәрләрендә Кайбыч ягы аһәңнәре дә яшеренгән.

2017

***Равил Сәйфетдинов***

*"Яшел Үзән"* газетасында бастырылган мәкалә, 2018, 25 апрель, №29.